Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советы

КАРАР

«26» май 2025 ел

№ 121

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советының 2024 елның 20 декабрендәге 110 номерлы карары белән расланган Түбән Бәрәскә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2024 елның 12 декабрендәге 89-ТРЗ номерлы «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 42 статьясына үзгәреш кертү хакында», 92-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Әтнә районы прокуратурасының 2025 елның 28 апрелендәге №02-08-02-2025/Прдп210-25-20920010 протесты нигезендә, Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советының 2024 елның 20 декабрендәге 110 номерлы карары белән расланган Түбән Бәрәскә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 3 бүлекнең 3.9 пунктында "2025 елның 1 гыйнварына" сүзләрен "2028 елның 1 гыйнварына" сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 16 бүлекнең 16.10 пунктындагы 3 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында http://atnya.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Түбән Бәрәскә авыл җирлеге башлыгы: Фатыхова А.В.